СОВЕТ БУГУЛЬМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН IV СОЗЫВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ IV ЧАКЫРЫЛЫШ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

от 13.12.2023г. г. Бугульма № 9

**ЕГЕРМЕ ТУГЫЗЫНЧЫ СЕССИЯ**

**«Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә автомобиль транспорты, шәһәр җир өсте электр транспорты һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Нигезләмәне раслау турында»2021 елның 17 ноябрендәге Бөгелмә муниципаль районы Советының XI сессиясенең 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте транспорты уставы» 08.11.2007 №259-ФЗ Федераль законның 3.1 статьясына, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында»08.11.2007 №257-ФЗ Федераль законның 13.1 статьясына ярашлы, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроле турында» 31.07.2020 №248-ФЗ Федераль законның 23 статьясындагы 9 өлеше белән, Татарстан Республикасы «Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 №131-ФЗ Федераль законы нигезендә,

Бөгелмә муниципаль районы Советы

Карар кабул итте:

1. Бөгелмә муниципаль районы Советының 2021 елның 17 ноябрендәге XI сессиясенең 6 номерлы карары белән расланган Автомобиль транспортында,

шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында нигезләмәнең 3 нче кушымтасына үзгәрешләр кертергә, аны кушымтага ярашлы рәвештә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы «Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставында билгеләнгән тәртиптә үз көченә керә һәм басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Бөгелмә муниципаль районы башлыгы урынбасары Ф.В. Мөхәммәтовка йөкләргә.

**Бөгелмә муниципаль районы Башлыгы** **Л. Р. Закиров**

Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә шәһәр җир өсте электр транспортын һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турында Нигезләмәгә 3 нче кушымта»

**Бөгелмә муниципаль районы торак пунктлары чикләрендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль үткәргәндә һәм планнан тыш контроль чарасын үткәрү һәм сайлау турында Карар кабул иткәндә куллана торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге**

1. Муниципаль контроль объектында автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында торак пункт чикләрендә һәм (яки) бер үк җирле әһәмияттәге юлда утыз көн дәвамында ике һәм аннан да күбрәк юл-транспорт һәлакәте.

2. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша бирелгән мәгълүматлар нигезендә, контрольдә тотылган зат йөртүчеләре тарафыннан бер календарь ел

дәвамында даими пассажирлар йөртү маршрутында автомобиль транспорты, шәһәр, җир өсте, электр транспорты белән юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозу очракларының биш процентка һәм аннан да күбрәккә артуы.

3. Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша бирелгән мәгълүматлар нигезендә, бер календарь ел эчендә юл инфраструктурасы объектында юл-транспорт һәлакәтләре санының алдагы календарь ел белән чагыштырганда ике һәм аннан да күбрәк тапкыр артуы.

4. Узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, контрольдә тотылган кешенең кулында булган яки файдаланган юл участогында календарь айда юл-транспорт һәлакәтләре санының биш процентка артуы (әмма ким дигәндә өч бозуга).

5. Хисап елы дәвамында юлның бер участогында яки юллар һәм урамнар киселешендә кешеләр зыян күргән яки яраланган юл шартлары белән бәйле рәвештә бер төр юл-транспорт һәлакәтенең барлыкка килүенең өч һәм аннан да күбрәк фактын ачыклау.